# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Яңа Шашы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

14” ноябрь 2023 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 14 ноябрендә “Сез 2024 елда Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Яңа Шашы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе оборона министрлыгы белән контракт төзегән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Яңа Шашы авылы территориясен чистарту, агачлар һәм куакларны кисү;
2) Яңа Шаши авылында зират өчен бензопила сатып алу;
3) Яңа Шашы авылында урам юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алу;

“РИЗА” “КАРШЫ”

Сез, 2023 елдагы экономияләнгән үзара салым акчасын, Яңа Шашы авылында урам юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алуга юнәлтергә ризамы

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 120 (бер йөз егерме) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 70 (җитмеш) кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 70 (җитмеш) кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Яңа Шашы авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.
2. “Сез 2024 елда Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Яңа Шашы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе оборона министрлыгы белән контракт төзегән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Яңа Шашы авылы территориясен чистарту, агачлар һәм куакларны кисү;
2) Яңа Шаши авылында зират өчен бензопила сатып алу;

Яңа Шашы авылында урам юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алу;
Сез, 2023 елдагы экономияләнгән үзара салым акчасын, Яңа Шашы авылында урам юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алуга юнәлтергә ризамы
мәсьәләсен кабул ителгән дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Яңа Шашы авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Яңа Шашыавылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.